КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 861

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 186 нчы; 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче; 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы; 2023 ел, 20 март, 297 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 2 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче карары белән расланган Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 2 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларын техник тикшергән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм диагностика картасының дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәрен саклауга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы карары белән расланган Транспорт чараларын техник тикшергән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм диагностика картасының дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәрен саклауга төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 2 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин